РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ**
**Большекляринского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Кариле**
**авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

ул. Советская, 9,с. Большие Кляри, 422837
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 04308901 ОГРН 1031638400364
ИНН/КПП 1622001763/162201001

Совет урамы, 9,Олы Кариле авылы, 422837,
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 04308901 ОГРН 1031638400364
ИНН/КПП 1622001763/162201001



**20 ноябрь 2020 ел** **№3**

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Кече Кариле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. ТР , Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Кариле авылы, Вахитов урамы, 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Кече Кариле авылындагы ФАП бинасында 2020 елның 09 декабрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Кече Кариле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Кече Кариле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым

кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Кече Кариле авылында Ишултан ,Кушкаен, Вахитов, Аръяк урамнары эчендәге юлларга вак таш түшәп төзәтү (вак таш ташу, таш салу, таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Кече Кариле авылында юлларны кардан чистарту, грейдлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Кече Кариле авылынында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу);

- Кече Кариле авылында җәйге чорда территориядәге чүп үләннәрен чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- вакытлыча каты көнкүреш калдыклары полигоннарын тоту һәм чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- янгын депосын һәм автоцистернаны тоту (АЦ-40 (131) өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;.

« ӘЙЕ»　　　　　　　　　　«ЮК».

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга):

-ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1;

-ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов урамы, 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге**
**башлыгы　　　　　　　　　　Ф.Г. Гарифуллин**